ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3; Ватаным Татарстан, 2015, 15 апрель) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очраклардан тыш, шушы Кодексның 2.8 статьясында, шулай ук 3.8, 3.11, 3.14, 3.15 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне, вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны тапшыру турында эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән килешүгә нигезләнеп, эчке эшләр органнарының (полициянең) вазыйфаи затлары төзи.»;

2) 14 өлештә «2.6, 2.7, 3.2, 3.6, 5.1, 5.2, шулай ук 2.12, 2.13, 3.3 – 3.5, 3.7» сүзләрен «2.6 – 2.8, 3.6, 3.8, 3.11, 3.14, 3.15, 5.1, 5.2, шулай ук 2.4, 2.5, 2.12 – 2.14, 3.2 – 3.5, 3.7, 3.10 (гражданнарга карата)» сүзләре белән алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 7; 2015, № 3), «2.6, 2.7, 2.12, 2.13, 3.2 – 3.7, 3.16» саннарын «2.4 – 2.8, 2.12 – 2.14, 3.2 – 3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14 – 3.16» сүзләре белән алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 25 апреле
№ 29-ТРЗ